РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

***Постановление*** ***Карар***

23.10.2020 **г. Чистополь** 220

Чистай шәһәр башкарма комитетының «Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2016 елның 27 июнендәге 96 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы боерыгын, «Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы һәм «Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 18 сентябрендәге 675 номерлы карарларын үтәү йөзеннән, Чистай шәһәр Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай шәһәр Башкарма комитетының «Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2016 елның 27 июнендәге 96 номерлы карары белән расланган стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына үзгәрешләр кертергә,
- 42 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

| № п/п | Стационар булмаган сәүдә объектының урнашу урыны | Сатыла торган товарның ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объекты тибы | Сәүдә урыннары саны | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| 42. | Чистай шәһәре, К. Маркс ур.,92 | азык-төлек булмаган товарлар | сәүдә павильоны | 36 | ел дәвамында |

- 44 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

| № п/п | Стационар булмаган сәүдә объектының урнашу урыны | Сатыла торган товарның ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объекты тибы | Сәүдә урыннары саны | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| 44. | Чистай шәһәре, К. Маркс ур.,92 | азык-төлек булмаган товарлар | сәүдә павильоны | 2 | ел дәвамында |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://chistopol.tatar.ru/) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Ф.М. Садыйковка йөкләргә.

Шәһәр Башкарма
комитеты җитәкчесе И.Ф. Рәхимов